СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2021 с. Сарманово № 58

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмә**

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 1 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмәне расларга.
2. «Сарман муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2011елның 23 декабрендәге 47 номерлы карарын (2014 елның 18 апрелендәге 148 номерлы, 2021 елның 31 маендагы 38 номерлы кертелгән карарлар нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча Сарман муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.
4. Әлеге карар кабул ителгән көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча Сарман муниципаль районы Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы Советы Рәисе Ф. М. Хөснуллин